ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16 12 2022 г. № 898

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 3 пунктына таянып, Түбән Кама муниципаль районы территориясендә мобилизацияләнүчеләр гаиләләренә ярдәм күрсәтү буенча 2022 елның 7 ноябрендәге Оператив штабның эшче утырышы беркетмәсенең 4 пункты нигезендә, махсус хәрби операциядә катнашучы һәм Түбән Кама муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гаиләләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм күрсәтү турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«2022 елның 7 ноябреннән мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның түбәндәге категорияләренә балалар караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве өлешенә өстәмә компенсация билгеләргә:

- икенче ата-анасы (законлы вәкиле) Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче, яки «Үзәк» гаскәрләре төркеме берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәр булган баланың (балаларның) ата-анасына;

- икенче ата-анасы (законлы вәкиле) «Барс» ирекле отрядларында («Илнең сугышчан армия резервы») Махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче булган баланың (балаларның) ата-анасына;

- икенче ата-анасы (законлы вәкиле) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче гражданнар, «Үзәк» гаскәрләре төркеме берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт үтүче гражданнар, шулай ук «Барс» ирекле отрядларында («Илнең сугышчан армия резервы») махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар сыйфатында махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) баланың (балаларның) ата-анасына».

Социаль ярдәмнең әлеге чарасы түбәндәгеләргә билгеләнүен билгеләргә:

- Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче граж-даннар, «Үзәк» гаскәрләре төркеме берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт үтүче гражданнарга карата – контракт гамәлдә булган срок чорына;

- «Барс» ирекле отрядларында («Илнең сугышчан армия резервы») махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарга карата - ирекleләр формированиесендә булу чорында.»;

карарга кушымтада:

1.3 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«- икенче ата-анасы (законлы вәкиле) Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче, яки «Үзәк» гаскәрләре төркеме берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәр булган баланың (балаларның) ата-анасына;

- икенче ата-анасы (законлы вәкиле) «Барс» ирекле отрядларында («Илнең сугышчан армия резервы») Махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче булган баланың (балаларның) ата-анасына;

- икенче ата-анасы (законлы вәкиле) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче гражданнар, «Үзәк» гаскәрләре төркеме берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт үтүче гражданнар, шулай ук «Барс» ирекле отрядларында («Илнең сугышчан армия

резервы») махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар сыйфатында махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) баланың (балаларның) ата-анасына.»;

2.1 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Икенче ата-анасы (законлы вәкиле) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган граждан, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче граждан, «Үзәк» гаскәрләре төркеме берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт үтүче граждан, «Барс» ирекле отрядларында («Илнең сугышчан армия резервы») махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче граждан булган, яисә икенче ата-анасы (законлы вәкиле) махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) баланың (балаларның) ата-анасына каралган компенсация билгеләү өчен, мөрәҗәгать итүче бала (балалар) йөри торган мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе аша Түбән Кама муниципаль районында компенсация түләү өчен кабул итү һәм билгеләү буенча вәкаләтле органга компенсация билгеләү турында гариза бирә. Компенсация билгеләү турында кергән гаризаларны мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы хәрби комиссарыннан алынган белешмәләр белән бергә гомумиләштерү һәм җибәрү өчен Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә белем бирү идарәсенә, Түбән Кама муниципаль районында кабул итү һәм компенсация түләүгә билгеләү буенча вәкаләтле органга җибәрәләр.»;

2.6 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче гражданнар, яки «Үзәк» гаскәрләре төркеме берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт үтүче гражданнар өчен хәрби хезмәтне тәмамлау;

2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

- «Барс» ирекле отрядларында («Илнең сугышчан армия резервы») махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар өчен ирекләләр формированиесендә булуны тәмамлау.

2. Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтүче, «Үзәк» гаскәрләре төркеме берләшмәләрендә һәм хәрби частьләрендә хәрби хезмәт үтүче гражданнар, «Барс» ирекле отрядларында («Илнең сугышчан армия резервы») махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар исемлеген, алга таба - хәрби хезмәтне тәмамлаган яки махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар исемлеген Татарстан

Республикасы Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы хәрби комиссарына (Ситдыйков Г.Ф.) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә белем бирү идарәсенә (Андрианова С.А.) җибәрүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәктәпкәчә белем бирү идарәсенә (Андрианова С.А.) Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы хәрби комиссарыннан (Ситдыйков Г.Ф.) әлеге карарның 2 пункты нигезендә кергән белешмәләрне, социаль ярдәм күрсәтү чаралары бирү максатларында, Түбән Кама муниципаль районында кабул итү һәм компенсация түләүгә билеләү буенча вәкаләтле органга һәм Түбән Кама муниципаль районының ведомство карамагындагы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми бастырылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г.Мәхмүтовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

Республика Татарстан МКУ «Исполнительный комитет Нижнекамского муниципального района» * Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ *
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874